СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.10.2025 г.Лениногорск № 19

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләп кую турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 5 пункты нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 48 статьясы белән, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына Шәмәрданов Илнур Әбдрәүф улын билгеләргә.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры М.Н.Гирфановка Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Шәмәрданов Илнур Әбдрәүф улы белән контракт төзергә.

3. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Шәмәрданов Илнур Әбдрәүф улына үз вазыйфаларын 2025 елның 31 октябреннән башкарырга керешергә.

4. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Лениногорск муниципаль районы Башлыгы, Совет рәисе М.Н.Гирфанов